# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Алексеевск муниципаль районының Урманасты Шонталысы авыл җирлегенең Ар.Баран авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**

16 декабрь 2021 е.

№ 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урманасты Шонталысы авыл җирлеге составына керүче Ар.Баран авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Алексеевск муниципаль районының Урманасты Шонталысы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, студентлар, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнар керми, һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:
- җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- карны чистарту;
- зиратларны төзекләндерү (материал сатып алу);
- терлекләр көтүен (плотиналарны) яхшырту.

2. Әлеге карарны Урманасты Шонталысы авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урманасты Шонталысы авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районының Урманасты
Шонталысы авыл җирлеге башлыгы А.А.Җиһаншин